**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮҖӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423734, Күҗәкә авылы, Совет урамы, 28 нче йорт.Тел.3-44-48

**СОВЕТ КУЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423734,село Кузякино, улица Советская, дом 28.Тел.3-44-48

**КАРАР**
**12.10.2020 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 5**

**Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2020 ел, 263-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 20 июнендәге 10 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлегендә бюджет процессы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-«2. Авыл җирлеге Советының тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турында закон проектын (карарларны) закон чыгару (вәкиллекле) органына карауга керткәннән соң кабул ителгән норматив-хокукый актлары агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Күҗәкә авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга»

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы Күҗәкә
авыл җирлеге Советы белән рәислек итүче — И.Н.Мусин